СОВЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15.05.2017 ел г. Мензелинск № 2

Дәүләт җирләре составына керә торган, милек хокукы чикләнмәгән җир кишәрлекләрен һәм муниципаль милекне арендалау шартнамәсен төзү хокукына җир кишәрлекләрен яисә аукцион уздырганда аукцион предметының башлангыч бәясен билгеләү турында (РФ Җир кодексы 39.18 статьяның 7 пункты нигезендә)

Татарстан Республикасы Минзәлә районы җирле бюджетының салым булмаган керемнәрен тулыландыру максатларында Россия Федерациясе Җир кодексының 39.11 маддәсенең 12 нче пункты, 13 нче пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Аукцион уздырганда РФ Җир кодексының 39.18 маддәсе 7 п.нигезендә аукцион предметының башлангыч бәясен билгеләргә:

1.1. җир кишәрлеген сату буенча - җир кишәрлегенең кадастр бәясе, әгәр дәүләт кадастр бәяләве нәтиҗәләре аукцион үткәрү турында карар кабул ителүгә биш ел кала расланса;

1.2. әгәр дәүләт кадастр бәяләве нәтиҗәләре аукцион үткәрү турында карар кабул ителгән датага кадәр биш ел элек расланса, җир кишәрлеген арендалау шартнамәсен төзү хокукына - кадастр бәясенең 1 (ун) %ы күләмендә.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http//pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Минзәлә муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе И.Т. Шагалиевка йөкләргә.

Совет рәисе А.Ф. Сәлахов